| | |
|---|---|
| ЛЕНИНОГОРСКИЙ<br>ГОРОДСКОЙ СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА | ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

13.10.2022 г.Лениногорск № 103

Лениногорск шәһәр Советының 2015 елның 25 мартындагы 189 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү эшен оештыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131- ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Лениногорск шәһәр Советының 2015 елның 25 мартындагы 189 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлегендә җирләү эшен оештыру турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2 бүлек 2 статьяның 4 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Ир яисә хатынга, якын туганнарга, башка туганнарга, законлы вәкилгә яисә вафат булган, җирләү эше мәсьәләләре буенча махсуслаштырылган хезмәт тарафыннан җирләү бурычын үз өстенә алган башка затка күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфаты түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

-җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү (үлем турында медицина таныклыгы, Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге тарафыннан бирелгән үлем турында таныклык), тиешле органнарга мөрәҗәгать иткән вакыттан алып бер тәүлек эчендә;

-үлгән кеше гәүдәсенең нинди моргта (өйдә) урнашкан булуы, җирләү датасы һәм вакыты, матәм процессиясе узу маршруты, кием үлчәме, мәрхүмнең

буе озынлыгы, автокатафалка хезмәтләренә заказ рәсмиләштерү тәртибен төгәлләштерүне үз эченә алган заказны гамәлгә ашыру;

- тыштан һәм эчтән тукыма белән тышланган агач табут биру;

-күмү өчен кирәкле предметлар биру;

-табутны һәм кирәкле әйберләрне бер адреска илтеп җиткерү, төяү-бушату эшләрен дә кертеп;

-табутка гәүдәне салу;

-табуттагы гәүдәне зиратка һәм алга таба күмү урынына китерү;

- кабер казу өчен урын билгеләүне, кышкы чорда күмеләсе урынны кардан чистартуны, кул ысулы белән кабер казуны, төбен чистартуны, кабер стенасын кулдан чистартуны үз эченә алган кабер (шул исәптән көлле урнаны күмү өчен) урнаштыру:

- күмү урыныннан табут алып чыгу һәм аны күмелгән урынга китерү, матәм йоласын көтү, табут капкачын ябу, табутны кабергә төшерү (көлле урнаны төшерү), каберне туфрак белән тутыру, кабер өстенә туфрак салу;

- кабер өстенә ритуаль теркәү билгесе биру һәм урнаштыру (күмелгән кешенең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне һәм үлем датасы.»;

2 бүлекнең 2 статьясын түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш белән тулыландырырга:

«5. Дин буенча гражданнарны күмүгә бәйле ритуаль хезмәтләр һәм җеназа ритуалы предметларының сыйфаты санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә, техник шартларга һәм гамәлдәге законнар нигезендә ритуаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә хезмәтләргә һәм продукциягә мәҗбүри таләпләр билгеләүче башка хокукый актларга туры килергә тиеш, шулай ук туганнарның теләкләрен исәпкә алып, дин кагыйдәләренә һәм тәртипләренә туры килергә тиеш.»;

2 бүлекнең 2 статьясындагы 5, 6, 7, 8 өлешләрен тиешенчә 6, 7, 8, 9 өлешләре дип санарга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми интернет-сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аны игълан иткән көннән (басылып чыккан) үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск шәһәре
муниципаль берәмлеге Башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры — Р.Г. Хөсәенов